**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Уразаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Энгельса д. 65, село Уразаево,
Азнакаевского муниципального района
РТ, 423330
Тел. (8-885592) 43555

Энгельс урамы ,65, Уразай авылы
Азнакай муниципаль районы ТР,
423330
Тел. (8-885592) 43555

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » август 2017 ел № 14

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Уразай авыл
җирлегенең уртача сроклы финанс планын
эшләү рәвешен һәм тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең уртача сроклы финанс планын эшләү тәртибе (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең уртача сроклы финанс планы рәвешен (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык: А.М.Шәрифуллина